


# ГАЙСӘНЕҢ ТУУЫ

[1]Ул көннәрдә Август кайсар тарафыннан бөтен Рим империясендәге бар кешеләрне исемлеккә теркәргә дигән боерык бирелде. [2]Бу теркәү беренче тапкыр уздырылды. Ул вакытта Сурия өлкәсе белән Күрини идарә итә иде. [3]Язылу өчен һәркем үз нәселе шәһәренә китте. [4]Йосыф та Гәлиләядәге Насара шәһәреннән Яһүдиягә, Давыт шәһәренә, Бәйтлехемгә китте, чөнки Йосыф Давыт нәселеннән иде. [5]Йосыф исемлеккә теркәлергә үзенә ярәшелгән Мәрьям белән бергә барды. Мәрьям авырлы иде. [6]Алар Бәйтлехемдә булганда Мәрьямнең бала табар вакыты җитте. [7]Мәрьям үзенең беренче Баласын — Ир Баланы тудырды. Ул Аны биләде һәм утлыкка салды, чөнки аларга кунак йортында урын булмады.





# КӨТҮЧЕЛӘР ҺӘМ ФӘРЕШТӘЛӘР

[8]Ул тирәләрдә шул төнне берничә көтүче кырда сарык
көтүе саклый иде. [9]Алар алдында Раббының бер фәрештәсе
пәйда булды, һәм алар булган урын Раббының даныннан
балкып китте. Көтүчеләр бик нык куркып калдылар.

[10]Фәрештә исә аларга
әйтте:



— Курыкмагыз!
Мин сезгә куанычлы
хәбәр — бөтен халык
өчен зур шатлык алып
килдем: [11]бүген Давыт
шәһәрендә сезнең өчен
Коткаручы туды. Ул —
Мәсих, Раббы![12] Менә
сезгә билге: сез Баланы табарсыз. Ул биләүгә биләнгән
булыр һәм утлыкта ятар.

[13]Кинәт фәрештә янында күп санлы күк фәрештәләре гаскәре күренде, һәм алар:

[14]— Күкләрдәге Аллаһыга дан!

Аллаһы илтифат күрсәткән кешеләргә җирдә иминлек! — дип Аллаһыны данладылар.

[15]Фәрештәләр күккә күтәрелгәннән соң, көтүчеләр бер-берсенә:



— Әйдәгез, Бәйтлехемгә барыйк, Раббы әйткән анда булган хәлне барып күрик, — диештеләр.

[16]Алар ашыгып
Бәйтлехемгә килделәр
һәм анда Мәрьям белән
Йосыфны һәм утлыкта яткан Баланы таптылар.[17] Баланы
күргәч, бу Бала хакында үзләренә хәбәр ителгәнне аларга
сөйләп бирделәр.[18] Көтүчеләр сөйләгәнне ишеткән кешеләр
барысы да хәйран калдылар. [19]Мәрьям исә боларның
һәммәсен күңеленә салып куйды һәм шул хакта уйлап
йөрде.

[20]Ишеткән һәм күргән барлык нәрсәләр өчен Аллаһыны данлап һәм мактап, көтүчеләр көтүләре янына кайттылар. Барысы да фәрештә әйткәнчә булды.

[21]Сигез көннән соң, Баланы сөннәткә утырту вакыты җиткәч, Аңа Гайсә дигән исем куштылар. Анасы Мәрьям балага узганчы ук фәрештә Аңа шушы исемне кушкан иде.

Иисус Христос
синеиӊ утслӊ янып торсын
син безне хенге кеше итеп
эшляй еракляр икинче бупсаӊ
Иисус Христос. Бэз синеӊ баларыӊ.

Мин сине бик яратан.
Сабилий

Библейски текст © Институт перевода Библии, Москва, 2000
*http://ibt.org.ru/ru/text?m=TTR&l=Luke.2&g=0*

Design & Layout: OM EAST - east.om.org

TT